**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422622 с. Сокуры,
ул. Школьная , д.1 , помещение 1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 нчы йорт,бина 1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2025 елның «27» ноябре** **33 номер**

## КАРАР

### «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 11 сентябрендәге 19 номерлы Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

1. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2025 елның 31 июленә үзгәрешләр белән) , «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» (2023 елның 17 апреленә үзгәрешләр белән)РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон белән, КАРАР БИРӘМ:

2. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 11 сентябрендәге 19 номерлы Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертергә.

1) **2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә «Физик затларны биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән шәхесне таныклаучы башка документ;

2) **2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«.2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 1 өлешендә каралган бирүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан бирелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге»;

3) **3.2.1.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

"Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә»;

4) **2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында** "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк»сүзләренә алмаштырырга.

2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлеш өстәргә:

«4.1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары вәкаләтләрен башкару өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы аша бирелгән очракта, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнарының мондый белешмәләрне күрсәтмичә мөрәҗәгать итүчегә мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Р. Мәүлиев**